| ГЛАВА НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА И ГОРОДА НУРЛАТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҺӘМ НУРЛАТ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 6 08.02.2021

Нурлат муниципаль районы башлыгының 2017 елның 17 октябрендәге 81 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районы башлыгы каршындагы эшкуарлык советы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Мөмкин булган коррупциоген факторларны булдырмау максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгының 2017 елның 17 октябрендәге 81 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районы башлыгы каршындагы Эшкуарлык советы турындагы Нигезләмәгә, Нигезләмәнең 3нче бүлегендә 3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

«3.9. Совет аның утырышында аның исемлек составындагы әгъзаларның яртысыннан артыгы булган очракта карар кабул итәргә хокуклы. Карар катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Совет утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч әһәмияткә ия. Совет карарлары беркетмә рәвешендә карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә рәсмиләштерелә. Совет утырышы беркетмәсенә Совет рәисе яисә Совет утырышында рәислек итүче һәм җаваплы сәркатип кул куя. ».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга : http://nurlat.tatarstan.ru/.

А.С. Әхмәтшин